ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ютазы урамы, 14А йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Albina.Ahmetshina1@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 14** **14 ноябрь 2025 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге составына керүче Бәйрәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 26 маддәсе нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 27 ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктының Бәйрәкә авылы Абдуллин урамы, Авангард урамы, Вахитов урамы, Кооперация урамы, Минһаҗев урамы буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2025 елның 28 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктының Бәйрәкә авылы Октябрь урамы, Пушкин урамы, Сельхозтехника урамы, Татарстан урамы буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2025 елның 28 ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктының Бәйрәкә авылы Тукай урамы, Ютазы урамы, 1 Май урамы, 8 Март урамы буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында " гы 2025 елнын 31 октябрендэ чыккан 2 нче номерлы гражданнар

җыены карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр гражданиннан 2026 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларының (ире (хатыны), ата-аналары, балалары) тыш; 2 төркем инвалидлар өчен бер тапкыр түләүне 300 сум күләмендә киметергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, ягъни түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә Сез ризамы:

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу, тракторчы белән техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));;

- Бәйрәкә торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (лампалар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү) ремонтлау;

- Бәйрәкә торак пунктында һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (һәйкәлне ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү);

-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (эчә торган һәм хуҗалык - көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитария саклау зоналары проектын эшләргә һәм расларга; санитария-санитария саклау зоналары проектының туры килүе турында эпидемиологик нәтиҗә, материаллар, җиһазлар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекне бетерү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));

- Бәйрәкә торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү ремонтлау, коймалар кору (зират территориясендә карт агачларны кисү, аларны химик эшкәртү (химик препаратлар сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү)).

« ӘЙЕ »          « ЮК »

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетына Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

7. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы: А.О.Әхмәтшина